| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.09.2024 Олы Кайбыч ав. №361/1

16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм җир кишәрлекләре хокук ияләренең тормыш, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга үтәү максатларында, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Федоровский авыл җирлеге, Федоровское авылы, Зур Кызыл ур., 2 ж/к - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) «Автотранспортны саклау» адресы буенча урнашкан, 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (кушымта).

2. 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 4 октябрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Федоровский авылы, Тутаев ур., 43 й. адресы буенча авыл клубында уздырырга.

3. Кадастр номеры 16:21:070101:84 булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проектында булган материаллар (текстлы һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча танышырга була: Кайбыч районы, Федоровский авылы, Тутаев ур., 43 й.

3.1. 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр җыю урыны итеп

Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

-«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ю.В. Журавлевага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024е.______ ____ номерлы
карарына кушымта

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ

**ПРОЕКТ**

№__________

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«_____»______________20__

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимен исәпкә алып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Федоровский авыл җирлеге, Федоровское авылы, Зур Кызыл ур., 2 ж/к - Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) «Автотранспортны саклау» адресы буенча урнашкан, 16:21:070101:84 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә Улитина Гөлфия Рәшит кызына рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Территорияләрне үстерү департаментының Татарстан Республикасында җирләрдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.Р.Хизбуллинга) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыгуга юнәлешен тәэмин итәргә (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Территорияләрне үстерү департаменты җитәкчесе** **А.И.Әхмәтҗанов**